**КАРАР**

**“10” ноябрь 2020 ел** **№ 2**

**Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Урта Курса авыл җирлеге Корайван авылында халык җыены нәтиҗәләре турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1,56 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, 2020 елның 10 ноябрендә түбәндәге мәсьәлә буенча үткәрелгән халык җыены нәтиҗәсе белән халык җыены беркетмәсе төзелде:

«Сез 2021 елда яшәү урыны буенча Арча муниципаль районы Урта Курса авыл җирлеге Курайван авылы территориясендә теркәлгән һәр балигъ булган кешегә, түләү күләме 400 сум тәшкил иткән көндезге формада укучы студентлардан, 80 яшьтән узган гражданнардан, тумыштан булган инвалидлардан тыш, 800 сум күләмендә үзара салым кертү һәм алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл иту иту буенча түбәндәге эшләргә юнәлдерү белән килешәсезме:

- зират коймасын ремонтлау өчен материаллар сатып алу һәм ремонтлау;
- урамнарны яктырту челтәрләрен ремонтлау, шул исәптән яктырткычлар, лампалар, изоляциялэнгэн чыбыклар, таймерлар, счетчиклар, автоматлар, җибәргечләр сатып алу һәм урнаштыру.

Аерым мәсьәләләр буенча экономия барлыкка килгән очракта, авыл җирлеге башкарма комитетына акчаны җыенда билгеләнгән башка мәсьәләләрне хәл итү өчен җибәрергә рөхсәт итәргә.

“ӘЙЕ” “КАРШЫ”

Халык җыены беркетмәсе нигезендә сайлау хокукына ия булган җыенда катнашучылар исемлегенә 53 кеше кертелгән, җыенда катнашучылар саны 32 кеше.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча халык җыенында катнашучылар тавышы түбәндәгечә бүленде:

"Әйе" позициясе өчен халык җыенында катнашкан 32 кеше тавыш бирде; “Каршы" позициясе өчен җыенда катнашкан 0 кеше тавыш бирде.

Бәян ителгәннәрдән чыгып, халык җыены карар итте:

1. Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Урта Курса авыл җирлегендә Курайван авылында халык җыенын булып узган дип танырга, халык җыены нәтиҗәләре дөрес.

2. «Сез 2021 елда яшәү урыны буенча Арча муниципаль районы Урта Курса авыл җирлеге Корайван авылы территориясендә теркәлгән һәр балигъ булган кешегә, түләү күләме 400 сум тәшкил иткән көндезге формада укучы студентлардан, 80 яшьтән узган гражданнардан, тумыштан булган инвалидлардан тыш, 800 сум күләмендә үзара салым кертү һәм алынган акчаларны

җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү итү буенча түбәндәге эшләргә юнәлдерү белән килешәсезме:

- зират коймасын ремонтлау өчен материаллар сатып алу һәм ремонтлау;

- урамнарны яктырту челтәрләрен ремонтлау, шул исәптән яктырткычлар, лампалар, изоляцияләнгән чыбыклар, таймерлар, счетчиклар, автоматлар, җибәргечләр сатып алу һәм урнаштыру Аерым мәсьәләләр буенча экономия барлыкка килгән очракта, авыл җирлеге башкарма комитетына акчаны җыенда билгеләнгән башка мәсьәләләрне хәл итү өчен җибәрергә рөхсәт итәргә.

ӘЙЕ» “КАРШЫ“

мәсьәләсе буенча карар кабул ителгән дип танырга.

3. Әлеге карарны халык күп җыела торган урыннарда мәгълүмат стендларына ТР, Арча районы, Корайван авылы, М. Гафури урамы, 9 йорт адресы буенча, интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Арча муниципаль районының рәсми сайтында http://arsk.tatarstan.ru веб-адресы буенча урнаштыру юлы белән игълан итәргә һәм Татарстан Республикасы Рәсми хокукый мәгълүмат порталында http://pravo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча бастырып чыгарырга.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары Регистрына кертү өчен җибәрергә.

Урта Курса авыл җирлеге башлыгы Р.Р. Вафина